Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Исәк авыл җирлеге Әлки авылы
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 12 ноябре 1 нче номерлы

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Исәк авыл җирлегендә Әлки авылы халык җыены

Карар чыгарды:

1. 2020 елда Исәк авыл җирлегендә Әлки авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эш төрен үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә җибәрергә:
- Әлки авылында юлларны ремонтлау.
3. Исәк авыл җирлегенең Әлки авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен (нәтиҗәләрен) игълан итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Исәк авыл җирлеге
башлыгы, халык җыенында
рәислек итүче _________ З. Р. Мөхәммәтҗанова

Халык җыены секретаре ____________Р.Х. Гайнетдинова